| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле функцияләрен йөкләү турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасы Рәисе мәнфәгатьләрендә эш алып баруны тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Терентьев Александр Михайловичка Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле функцияләрен башкаруны йөкләргә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле функцияләрен йөкләү турында» 2024 елның 15 ноябрендәге 882 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 24 сентябрь
№ 781